| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**20.04.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 843** |

Зеленодольск шәһәрендә мемориаль такталар кую тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Мемориаль такталарны проектлауны, әзерләүне һәм куюны тәртипкә салу, тарихта күренекле вакыйгаларны , шулай ук аларның эшчәнлеге өлкәсендә казанышлары Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Зеленодольск шәһәре өчен озак вакытлы файда китергән шәхесләрне мәңгеләштерү турында карарлар кабул итү критерийларын билгеләү максатларында,«Татарстан Республикасында мемориаль такталар кую тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 елның 01 апрелендәге 163 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәрендә мемориаль такталар кую тәртибе турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Зеленодольск шәһәрендә мемориаль такталар кую буенча комиссия составын расларга (2 нче кушымта).
3. Зеленодольск шәһәрендә мемориаль такталар кую буенча комиссия турында нигезләмәне расларга (3 нче кушымта).
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районының
Башкарма комитеты
карарына
1 нче кушымта
20.04.20021 ел, № 843

**Зеленодольск шәһәрендә
мемориаль такталар кую тәртибе турында
нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Мемориаль такта - фән һәм техника, мәдәният, сәнгать һәм мәгарифне үстерүгә, гражданнарның сәламәтлеген, тормышын һәм хокукларын саклауга, Ватан алдындагы хәрби батырлыклары һәм башка казанышлары өчен зур өлеш керткән күренекле шәхесләр, Зеленодольск шәһәре, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе тормышында истәлекле тарихи вакыйгалар һәм даталар истәлеген мәңгеләштерү өчен билгеләнгән тарих һәйкәле булмаган (сәнгать әһәмиятенә ия һәм монументаль сәнгать объектларына кергәннән тыш) истәлекле билгедән гыйбарәт монументаль сәнгать формаларының берсе.

Биналарда, корылмаларда яки бүлмәләрдә куела торган һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән вакыйгаларны һәм даталарны мәңгеләштерү белән бәйле булмаган теләсә нинди башка мәгълүмати билгеләр (такталар) мемориаль булып тормый.

1.2. Мемориаль такталар биналар, корылмалар фасадларында, кайчакта мөһим тарихи вакыйгалар булган урыннар һәм истәлекле урыннар интерьерларында, күренекле шәхесләр яшәгән яки эшләгән, шулай ук күренекле гражданнар яки тарихи вакыйгалар хөрмәтенә урамнар исемнәре булган очракларда куела.

1.3. Бинадагы, корылмадагы мемориаль такта бина, корылма хуҗалык алып бару яки оператив идарә милек хокукында булган юридик яки физик зат ризалыгы белән билгеләнергә мөмкин.

1.4. Мемориаль такталарның тексты Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә - татар һәм рус телләрендә бәян ителергә тиеш.

1.5. Мемориаль такта кую белән Россия Федерациясе гражданнарының да, башка дәүләтләр гражданнарының да истәлекләре мәңгеләштерелергә мөмкин.

1.6. Мемориаль такталар кую, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты Мәдәният идарәсе тарафыннан тапшырылган материалларны карау йомгаклары буенча, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кабул ителгән карары , һәм Зеленодольск шәһәрендә мемориаль такталарны кую комиссиясе карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.7. Мемориаль такталарны проектлау, әзерләү һәм кую буенча эшләрнең заказчысы булып үтенечнамә бирүче оешмалар чыга, муниципаль заказ очрагында-Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты.

1.8. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мемориаль такта кую турында карары массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырыла.

## II. Гражданнар һәм вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү өчен нигезләр

2.1. Мемориаль такта кую турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

– Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Зеленодольск шәһәре тарихындагы вакыйганың әһәмияте;

– дәүләт, иҗтимагый, сәяси, хәрби, җитештерү эшчәнлегендә, фәндә, техникада, әдәбиятта, сәнгатьтә, мәдәнияттә, спортта танылган казанышлар булу, шулай ук Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Зеленодольск шәһәре файдасына китергән эшчәнлекнең билгеле бер өлкәсенә шәхеснең аерым бер өлеше, Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләр тарафыннан бу казанышлары киң таныган очракта.

2.2. Мемориаль такта түбәндәге гражданнар хөрмәтенә куелырга мөмкин:

– эшчәнлекнең төрле тармакларын үстерүгә зур өлеш керткән һәм дәүләт бүләкләре булган;

– Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Зеленодольск шәһәре файдасына героик яки башка күренекле гамәлләр кылган.

## III. Мемориаль такта кую кагыйдәләре

3.1. Әлеге вакыйганың тарихи яки мәдәни әһәмиятен объектив бәяләү максатларында яисә исемен мәңгеләштерү тәкъдим ителә торган затның кимендә:

- вафат булганнан соң 1 ел узгач исеме мәңгеләштерү;
- вакыйгадан соң 5 ел узгач куела.

3.2. Мемориаль такталар Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройларына, Дан орденының тулы кавалерларына, вафат булганнан соң, соңгы елларда яшәгән йортта яки пенсиягә чыгу алдыннан эшләгән яки хезмәт иткән оешма бинасында куела.

## IV. Мемориаль тактаның тышкы кыяфәтенә таләпләр

4.1. Мемориаль такталар бары тик чыдам материаллардан (мәрмәр, гранит, чуен, бронза һәм башка металлардан) ясала.

4.2. Мемориаль такта тексты кыска формада бәян ителергә һәм мемориаль тактага багышланган затның казанышлары, вакыйгалары,

уңышлары яисә яшәү чорлары (эшчәнлек) турында белешмәләр булырга тиеш.

4.3. Мемориаль такта текстында ул билгеләнә торган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса) күрсәтелергә тиеш.

4.4. Мемориаль такталар композициясенә, тексттан тыш, портрет сурәтләре, декоратив элементлар да кертелергә мөмкин.

## V. Мемориаль такта куюю турындагы үтенечнамәне рәсмиләштерү тәртибе

5.1. Мемориаль такта куюның инициаторлары (алга таба - инициатор) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар, шулай ук кимендә 10 кеше булган гражданнар төркеме була ала.

5.2. Мемориаль такта кую өчен инициатор Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсенә түбәндәге документларны тәкъдим итә:

– мемориаль такта кую кирәклеген нигезләп, гариза (үтенечнамә);

– рәсми документлар нигезендә тулы биографик яки тарихи белешмә;

– вакыйганың дөреслеген яки исемен мәңгеләштергән затның казанышларын раслый торган архив һәм башка документлар күчермәләре;

– Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белгечләре тарафыннан расланган тиешле телләрдә мемориаль такта тексты проекты;

– Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты баш архитекторы тарафыннан килештерелгән мемориаль такта эскизы;

– мемориаль такта куюның фаразланган урыны турында белешмәләр (мемориаль такта куела торган урынын күрсәтеп бинаның фотолары, бүлмәнең интерьеры );

– истәлеге мәңгеләштерелә торган затның, әлеге бинада яшәү чорын күрсәтеп, тиешле торак-эксплуатацияләү предприятиеләреннән документлар;

– мемориаль такта куюга кулланучының яисә йорт (бина) милекчесенең ризалыгы;

– мемориаль тактаны проектлауга, әзерләүгә һәм куюга чыгымнарның гомуми сметасы һәм аны финанслау чыганаклары турында белешмәләр;

– мемориаль тактаны проектлау, әзерләү, кую һәм тантаналы ачуны тәэмин итү чаралары өчен түләү йөкләмәсе белән инициаторның гарантияле хаты;

– Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы белән килештерү.

5.3. Инициатор тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5.2 пункты нигезендә тапшырылган документлар Зеленодольск шәһәрендә (алга таба - Комиссия) мемориаль такта кую комиссиясе тарафыннан карала.

5.4. Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

Комиссия составына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, иҗади һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә. Кирәк булган очракта, Комиссия үз эшенә төрле оешма һәм ведомство белгечләрен җәлеп итә ала.

5.5. Комиссия кергән документларны карый һәм документлар кергән көннән бер ай эчендә мемориаль такта кую мөмкинлеге турында карар кабул итә.

5.6. Комиссия мемориаль такта кую турында уңай карар кабул иткән очракта, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, шундый карар кабул ителгән көннән алып бер ай эчендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына тиешле карар проектын тәкъдим итә.

Проектка кушымта итеп түбәндәгеләр бирелә:

– Комиссия утырышы беркетмәсе яки беркетмәдән өземтә;
– мәңгеләштерелә торган вакыйга яисә зат турында гомуми белешмәләр;
– мемориаль такта куюның фаразланган урыны турында мәгълүмат;
– мемориаль тактаны проектлау, әзерләү һәм кую буенча эшләрне финанслау чыганаклары турында белешмәләр.

Комиссия тарафыннан тискәре карар кабул ителгән очракта, инициаторга бу хакта мондый карар кабул ителгән көннән 15 көн эчендә хәбәр ителә.

## VI. Мемориаль такталарны кую, карап тоту һәм исәпкә алу тәртибе

6.1. Мемориаль такталарның зурлыгы һәм урыны Комиссия утырышында карала һәм килештерелә. Мемориаль тактаны кую биналар, корылмалар һәм инженерлык челтәрләренең конструкцияләренә зыян китерергә тиеш түгел.

6.2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты мемориаль такта кую турында карар кабул ителгәннән соң, инициатор аны әзерләү һәм кую чараларын гамәлгә ашырыла.

6.3. Кирәк булган очракта (бинаның, корылманың алгы ягы канәгатьләнмәслек хәлдә булганда) инициатор мемориаль тактаны ачу тантанасын үткәргәнче бинаның, корылманың алгы ягына ремонт башкара.

6.4. Торак һәм торак булмаган йортлар (күпфатирлы торак йортлардан тыш) биналарына куелган мемориаль такталарны инициатор бинаның милекчесе (аннан файдаланучы) балансына тапшыра яки аларны куйган оешма балансына кабул ителә.

Күпфатирлы торак йортлар биналарына куелган мемориаль такталарны инициаторлар территорияләрендә әлеге күпфатирлы торак йортлар урнашкан Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты балансына тапшыра яки аларны куйган оешма балансына кабул ителә

6.5. Мемориаль такталарны исәпкә алу һәм аларның торышын тикшерү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе

тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.6. Мемориаль тактаны алу турында карар (аны реставрацияләү таләп ителгән яки такта куелган бинада ремонт-реставрация эшләре үткәрелә торган очраклардан тыш) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

## VII. Мемориаль такталарны проектлау, әзерләү һәм кую чыгымнарын финанслау

7.1. Мемориаль такталарны проектлау, әзерләү һәм кую буенча чыгымнарны үтенечнамә белән чыгыш ясаган як түли.

7.2. Мемориаль такталар булдыруга муниципаль заказ Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан зур иҗтимагый әһәмияткә ия булган монументаль сәнгать өлкәсендә иҗади проектларның югары сәнгать дәрәҗәсен тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла һәм тулысынча инициатор тарафыннан финанслана.

## VIII.Мемориаль такталарны саклау һәм куллану кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылык

8.1. Мемориаль такталарның сакланышын тәэмин итү кагыйдәләрен үтәмәүдә гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы.

8.2. Билгеләнгән мемориаль тактага зыян салган затлар аны элеккеге халәттә торгызырга, ә мөмкин булмаганда, гамәлдәге законнар нигезендә зыяннарны капларга тиеш.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1нче кушымта

20.04.2021 №843

**Зеленодольск шәһәрендә**
**мемориаль такталар кую буенча комиссия**
**составы**

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Ганиев<br>Ильяс Рәсим улы | -Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |

**Рәис урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Лулаков<br>Денис<br>Владиславович | - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |

**Комиссия секретаре:**

| | |
|---|---|
| Захарова<br>Венера Марсель кызы | -Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр бүлеге баш белгече; |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Бызин<br>Николай Сергеевич | -Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Кадникова<br>Эльза Ренат кызы | -Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Хисаметдинов<br>Рөстәм Рәшит улы | -Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Старостин<br>Александр<br>Владимирович | -Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; |
| Усманов<br>Марат Зәкәри улы | -Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; |
| Афанасьева<br>Рәисә Вәли кызы | -Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгы |
| Нурмөхәммәтов<br>Әмир Җәмил улы | - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы; |
| Сергеев<br>Павел Николаевич | -«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте |

| | |
|---|---|
| | идарәсе» МБУ җитәкчесе; |
| Фәттахова Лилиана Альянс кызы | -Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы; |
| Шакиров Марат Госман улы | -Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге начальнигы; |
| Дёгтева Ольга Павловна | - «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Грузков Илья Вячеславович | - «Зеленодольск муниципаль районы ТКХ департаменты» МБУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Сафонов Михаил Викторович | – Җитәкче урынбасары - «Зеленодольск муниципаль районы архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ баш архитекторы |
| Пименова Наталья Николаевна | - «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» МКУ җитәкчесе; |
| Шаһиязданова Алинә Фәргать кызы | -ТР Зеленодольск муниципаль районында Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча); |
| Гыйззәтуллин Тәлгать Рифкат улы | -Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе; |
| Батршин Рамил Хәмзә улы | -Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы хәрби комиссары (килешү буенча); |
| Ханбиков Айрат Равил улы | -Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча башлыгы (килешү буенча); |
| Хәлиуллин Зөфәр Менхәт улы | - Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең ДЯКХ ФЯКХ 8 федераль янгын сүндерү-коткару отрядының башлыгы (килешү буенча); |
| Ардыханов Радик Равил улы | - Зеленодольск муниципаль районы буенча дәүләт янгын күзәтчелеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

Зеленодольск муниципаль районының
Башкарма комитеты карарына
3 нче кушымта

20.04.20021 ел, № 843

**Зеленодольск шәһәрендә мемориаль такталар кую буенча комиссия турында нигезләмә**

Зеленодольск шәһәрендә мемориаль такталар кую буенча Комиссия Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан фән һәм техника, мәдәният, сәнгать һәм мәгарифне үстерүгә, гражданнарның сәламәтлеген, тормышын һәм хокукларын саклауга, Ватан алдындагы хәрби батырлыклары һәм башка казанышлары өчен зур өлеш керткән күренекле шәхесләр, Зеленодольск шәһәре, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе тормышында истәлекле тарихи вакыйгалар һәм даталар истәлеген мәңгеләштерү буенча килешенгән чараларны эшләү максатларында төзелә (алга таба - Комиссия).

Комиссия составына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, иҗади һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә. Кирәк булган очракта, Комиссия үз эшенә төрле оешма һәм ведомство белгечләрен җәлеп итә ала.

Комиссия Комиссия рәисеннән, Комиссия рәисе урынбасарыннан, Комиссия әгъзаларыннан һәм Комиссия секретареннән тора.

Комиссия утырышында рәислек итүче:

- утырышны үткәрүне тәэмин итә һәм аның вакытын билгели;
- Комиссия әгъзалары арасында агымдагы вазыйфаларны бүлә;
- Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җавап бирә.

Комиссия секретаре:

- Комиссия утырышының көн тәртибе проектын һәм Комиссия утырышына материаллар әзерләүне тәэмин итә;
- Комиссия утырышына кадәр 4 көннән дә соңга калмыйча, Комиссия әгъзаларын утырышка чакыруны тәэмин итә һәм утырышның көн тәртибенә җибәрә;
- Комиссия әгъзаларын Комиссия тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча мәгълүмати-аналитик документлар белән тәэмин итә;
- Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;
- Комиссия эшен тәэмин итү өчен кирәкле башка вазыйфаларны башкара.

Комиссия әгъзалары:

- Комиссия утырышларында шәхсән, яисә җаваплы вәкилне җибәреп катнашалар;
- утырышта катнашу мөмкин булмаса яки җаваплы вәкил булганда бу хакта Комиссия рәисенә хәбәр итәләр;

- Комиссия секретаренә Комиссия эше буенча тәкъдимнәр һәм Комиссия утырышында каралырга тиешле мәсьәләләр буенча документлар тапшыра алалар.

Комиссия утырышы инициаторы тарафыннан документлар бирелгән саен уздырыла һәм, әгәр анда Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия утырышлары графигы Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- Комиссия утырышының беркетмә номеры һәм датасы;
- утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре;
- Комиссия утырышының көн тәртибе;
- карала торган һәр мәсьәлә буенча тавыш бирү нәтиҗәләре;
- Комиссиянең һәр гражданга карата чыгарылган карары;
- Комиссия әгъзаларының язма рәвештә бирелгән тәкъдимнәре һәм искәрмәләре.

Беркетмәгә Комиссия секретаре кул куя, Комиссия рәисе раслый .